СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 283 от 25.02.2019
На № _____ от ___________

# КАРАР

2018 елда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2019 елга бурычлар турында

Саба муниципаль районы башлыгы Р.Н. Миннихановның “2018 елда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2019 елга бурычлар турында”гы докладын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң Саба муниципаль район Советы 2019 елга төп бурычлар итеп финанс-икътисад эшчәнлекнең тотрыклы нәтиҗәләренә ирешүне, халыкка яшәү һәм эшләү өчен уңай шартлар тудыруны, аның куркынычсызлыгын тәэмин итүне, авыл хуҗалыгы, сәнәгать өлкәсен үзгәртеп коруны, инвесторлар җәлеп итүне, урта һәм кече эшмәкәрлекне үстерүне, бюджетка керемнәр кертүне тәэмин итүне, милләт-, конфессия ара һәм гражданлык килешүен ныгытуны, җирле үзидарү органнарын үстерүгә шартлар тудыруны билгеләп үтә.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып Татарстан Республикасы Саба муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Саба муниципаль районы башлыгы Р.Н. Миннихановның “2018 елда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2019 елга бурычлар турында”гы докладын игътибарга алырга.

2. 2019 елның 1 апреленә кадәр Саба муниципаль районы Башкарма комитетына докладта әйтелгән бурычларны тормышка ашыру буенча план расларга.

3. Шәһәр һәм авыл җирлекләре башлыкларына:

- территорияләрне, шәхси хуҗалыкларны комплекслы социаль-икътисадый үстерүгә аерым игътибар бирергә;

- эшсезлекне, халыкның рәсмиләштерелмәгән мәшгульлеген киметү өстендә эшне көчәйтергә;

- урта һәм кеше эшмәкәрлекне үстерү юлын, үзара салым чараларын кулланып җирлек бюджетларына өстәмә керем кертү өстендә максатчан эш алып барырга;

- электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүгә игътибарны арттырырга;

- яшьләрне авыл җирендә төпләнеп калдыру максатында кредит бирү һәм торак төзелеше өлкәсендә тормышка ашырылып килүче программалар мөмкинлекләрен максималь кулланырга;

- халыкның тормыш дәрәҗәсен түбән төшермәү һәм гражданнарга социаль хезмәтләргә тигез мөмкинлекләрне бирүне тәэмин итү чараларын күрергә;

- торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү, җирлек биләмәләрендә экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча эшне дәвам итүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны һәм Саба муниципаль районы Башлыгы докладын Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы сайтында http://saby.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.Р.Закирҗановка йөкләргә.

| | |
|---|---|
| Саба муниципаль районы Башлыгы | Р.Н. Минниханов |

СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ •